КАРАР (РЕШЕНИЕ)

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мишә авыл җирлеге составына керүче Сабабаш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

24.10.2024 ел № 2

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары , 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Саба муниципаль районы Мишә авыл җирлеге Уставының 22 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мишә авыл җирлеге Советының 25.10.2019 елның 22 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мишә авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында " карарына таянып 2024 елның 24 октяберендә узган гражданнар җыенында «2025 нче елда Саба муниципаль районы Мишә авыл җирлегенә керүче Сабабаш торак пунктында, яшәү урыны буенча Саба муниципаль районы Мишә авыл җирлегенең Сабабаш торак пункты составына теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1500,0 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме? " мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешенә җибәрү турында:

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту. (Сабабаш торак пунктында юлларны карап тоту һәм ремонтлау)

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган, гражданнар җыенына 330 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 169 кеше тавыш бирүдә катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 169 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1.Саба муниципаль районы Мишә авыл җирлеге составына керүче Сабабаш торак пунктында халык җыенын үткән дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре – чын мәгънәсендә дип танырга.

2. «2025 нче елда Саба муниципаль районы Мишә авыл җирлеге Сабабаш торак пунктында Саба муниципаль районы Мишә авыл җирлеге составына керүче Сабабаш торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1500,0 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?” дигән мәсьәлә буенча карар кабул итәргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге киләсе мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

1) - Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту. (Сабабаш торак пунктында юлларны карап тоту һәм ремонтлау)

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Мишә авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/mesha адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мишә авыл җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында
рәислек итүче,
Мишә авыл
җирлеге башлыгы А.Х.Гатиятуллин